РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

СОВЕТ
Нижнекамского муниципального района

423570, г.Нижнекамск, пр.Строителей,12
факс (8555) 41-70-00, тел.42-41-41

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

Түбән Кама муниципаль районы
СОВЕТЫ

423570, Түбән Кама шәһәре, Төзүчеләр пр., 12
факс (8555) 41-70-00, тел.42-41-41

---

РЕШЕНИЕ

КАРАР

№ 36

2020 елның 21 декабре

Түбән Кама муниципаль районы Советының «Татарстан Республикасы «Түбән Кама муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең административ комиссиясе регламентын раслау турында» 2006 елның 9 июнендәге 30 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

«Муниципаль районнарның һәм шәһәр округларының җирле үзидарә органнарына административ комиссияләр төзү һәм аларның эшчәнлеген оештыру буенча Татарстан Республикасы дәүләт вәкаләтләрен бирү турында» 2005 елның 30 декабрендәге 144-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә, Түбән Кама муниципаль районы Советы

КАРАР БИРӘ:

1. Түбән Кама муниципаль районы Советының 2006 елның 9 июнендәге 30 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы «Түбән Кама муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең административ комиссиясе регламентына түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1.1 пунктында «булдырылган» сүзен «төзелгән» сүзенә алмаштырырга, «булдыру буенча» сүзләрен «төзү буенча» сүзләренә алмаштырырга;

1.5, 1.7, 3.1 пунктларында «булдыру буенча» сүзләрен «төзү буенча» сүзләренә алмаштырырга.

3.7 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Административ комиссия карары буенча, утырышта катнашучы һәм коммерциячел яисә закон белән саклана торган башка серне саклау, гражданнарның шәхси тормышының кагылгысызлыгын саклау зарурлыгына һәм ачыктан-ачык фикер алышу эшне дөрес тикшерүгә комачауларга мөмкин булган яисә күрсәтелгән серләрне ачып салуга яки гражданның хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен бозуга китерә торган бүтән шартларга сылтау итүче заттан үтенеч кергән очракта, аның утырышы ябык режимда үткәрелә. Ябык утырышларда административ комиссия әгъзалары, хокук саклау органнары җитәкчеләре һәм махсус чакырылган затлар гына катнашырга хокуклы.»

3.18 пунктында «игълан итә» сүзен «игълан итәргә хокуклы» сүзенә алмаштырырга.

3.22 пунктта «ун» сүзен «тугыз» сүзенә алмаштырырга.

5.3, 5.6 пунктларында «утыз» сүзен «алтмышынчы» сүзенә алмаштырырга.

2. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны җирле үзидарә, регламент һәм хокук тәртибе мәсьәләләре буенча даими комиссиягә йөкләргә.

Түбән Кама муниципаль
районы Башлыгы

А.Р.Метшин